күп профильле
181 нче мәктәп

# Күкнең җиденче катында

## Мәктәп яңалыклары...

6нчы чыгарылыш
28 нче февраль

**БУ САНДА:**

| | |
|---|---|
| Бәйрәм белән! | 1 |
| Яңалыклар | 2 |
| Истәлекле көннәр | 3 |
| Котлыйбыз! «Туган тел көне” | 4 |




23 февраль —
Ватанны саклаучылар коне – батырлык, намус һәм кыюлык көне белән ихластан котлыйбыз сезне, егетләребез.
Сезгә һәм якыннарыгызга тыныч күк йөзе, ныклы сәламәтлек, бәхет-шатлык, рухи һәм матди байлык, һәр эшегездә бары тик уңышлар гына телибез.
Мөбәрак булсын матур бәйрәмегез!!!

# Мәктәп яңалыклары...

Мәркәзебез Казанда 2008 нче елдан бирле “Зур тәнәфес” бәйгесе уздырыла, анда быел  162 мәктәп катнашты. Иң сәләтле балалар үз осталыкларын күрсәттеләр. Төп бүләк-1 млн. акча. Ул уку бинасының инфраструктурасын яхшырту өчен биреләчәк.

Мәктәбебез дә бу бәйгедә үз көчен сынады. Сәләтле балаларыбыз җырга-моңга, нәфис сүзгә осталыкларын, биюгә сәләтле булуларын күрсәтеп, тамашачыларны, жюри әгъзаларын сокландырып, 2 нче турга уздылар.

Аларга уңышлар теләп калабыз!

7 нче февраль  көнне мәктәбебезгә, “Эшлекле чәй”гә,  врач-невролог, рефлексотерапевт Садыйова Гөлнара Далис кызы килде.

Ул укучыларны кызыксындырган сорауларга җавапларын бирде. Үзенең тормышы, эше белән таныштырып, укуга теләк уяту серләрен өйрәтте.

Укучылар бик канәгать калдылар.

11 нче февральдә безнең мәктәптә туган тел укытучыларының республика семинары булды. Семинарда укытучыларыбыз дәресләр, мастер- класслар күрсәттеләр.  ТР атказанган сәнгать эшлеклесе, Сажидә Сөләйманова премиясе лауреаты шагыйрә Шәмсия Җиһангирова белән очрашу укучылар, укытучылар күңелендә мәңгегә сакланып калыр.

Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген.

Нәрсәдән бу?- Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!..диеп 20нче февральдә 1нче Д сыйныфы укучылары Габдулла Тукай әдәби музеена "Әлифба бәйрәме"нә бардылар. Әлеге бәйрәмдә балалар рәхәтләнеп күңел ачтылар, бәйрәм кунагы Шүрәленең кызыклы биремнәрен үтәделәр, өйрәнеп килгән шигырьләрен сөйләделәр, җырладылар, биеделәр.

21 –22 нче февраль көнне мәктәбебездә, 2-9 нчы сыйныфлар арасында,  “Строй һәм җыр смотры” булып узды.

Укучылар бик әзерләнгәннәр һәм күп көч куйганнар иде.

Алар матур чыгышлары белән сокландырдылар.

1 нче март көнне мәктәбебездә “Ягымлылык-иң зур бүләк”ярминкәсе узды.Укучыларыбыз ярминкәгә  кул эшләре алып килгәннәр иде.

Бу ярминкә “Ветеранга билет” проектын тормышка ашыру максатыннан оештырылды. Җыелган акчаларга сугыш ветераннарына бүләкләр алыначак.

Мельникова Аделина, гәҗит хәбәрчесе

# *Истәлекле көннәр...*

*Бер матур җыр идең син үзең дә,*
*Гомерең дә калды җыр булып...*

*1906нчы ел, 15нче февраль – герой-шагыйрь - Муса Җәлилнең туыуына*
*-113 ел.*



**Муса Җәлилне белмәгән кеше сирәктер. Үзенең тиңдәшсез батырлыгы, кыюлыгы, шигырьләренең аһәңлелеге, яңгырашы белән күп кешене сокландыра ул. Укучылар аның шигырьләрен бик яратып укыйлар, ятлыйлар, хәтта үзләре дә аңа багышлап шигырьләр иҗат итәләр.**

**Муса абыйга.**

**Нәни чактан бик яратып,**
**Укыдым шигырьләрен,**
**“Күке”, “Куян” кебекләрен**
**Беләдер инде һәркем.**
**Зурлар да ярата аның**
**Шигырьләрен укырга.**
**“Вәхшәт”, “Зиндан” шигырьләрен**
**“Үлемсез җыр”, “Төрмә” сен.**
**Муса абый шигырьләре**
**Уйландыра,елата.**
**Кайчак бармак янап ала,**
**Безне уйга калдыра.**
**Герой-шагыйрь - Муса Җәлил**
**Тугансың син февральдә.**
**Чәчәк бәйләмнәрен куям,**
**Котлап туган көнеңдә.**

**Мельникова Аделина, 5 “Д”сыйныф укучысы**

күп профильле
181 нче мәктәп

Тулпар урамы, 2нче йорт

Телефон: 89050229576

Эл. почта: gabdullazyanova1979@mail.ru

Безнең девизыбыз:

«Без-өлгерләр!»

Хөрмәтле укытучыларыбыз!

Сәйфуллина Мария Леонид кызы (04.03)

Сөнгатуллина Гөлназ Мөнир кызы (07.03)

Чумарова Наталья Петровна (08.03)

Вәлиуллина Әлфинур Факил кызы (12.03)

Каюмова Наилә Рамил кызы (17.03)

Габдуллаҗанова Айсылу Фәрид кызы (18.03)

Исмәгыйлева Әлфия Идрис кызы (21.03)

Сезне туган конегез белән ихлас котлыйбыз.Бәхетле, озын гомер телибез!



Озын гомер, ак бәхетләр
Сезгә бездән теләкләр.
Шушы кызыл розалар,
Булсын Сезгә бүләккә!

## 21 февраль – Халыкара туган тел көне.

Бәйрәмне билгеләп үтү көне итеп 21 февраль юкка гына сайланмаган, чөнки 1952 нче елның шушы көнендә Пакистанда 5 студент үтерелә. Алар бангла телләрен дәүләт теле итүне таләп итәләр. Соңрак Пакистанда Бангладеш дип аталучы мөстәкыйль дәүләт барлыкка килә. Шушы вакыйгадан соң 47 ел үткәч, 1999-нчы елда, 21 февраль Бангладеш тәгъдиме белән ЮНЕСКО тарафыннан Халыкара туган тел көне дип игълан ителә.

Татар теле

Татар теле- туган телем,
Минем газиз, үз телем.
Туган телем татар телен
Беләм һәм дә сөйләшәм.

Кайда гына яшәсәк тә,
Кемнәр генә булсак та,
Телебез белән мактанып
Яшик без горурланып.

Татар теле бай тел бит ул,
Үзе серле һәм моңлы.
Үз телемдә эндәшәм мин,
Үз телемдә моңланам.

Мәхмүтова Мәдинә, 5 «Е» сыйныфы укучысы

Редколлегия:
Мәхмүтова Мәдинә, Мәхмүтова Мәликә, Хөснетдинова Камилия, Вәлиева Диләрә,Корчагина Яна, Хәсәнова Адилә, Мельникова Аделина
Җитәкчесе:А.Ф.Габдуллаҗанова